**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 26 декабрендәге 5361 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 декабрендәге 5253 номерлы**
**«Казан шәһәренең Киров районында ачык сервитут**
**билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Техник хаталар җибәрелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 декабрендәге 5253 номерлы «Казан шәһәренең Киров районында ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 2 номерлы кушымтаны әлеге карарның кушымтасы нигезендәге редакциядә бирергә.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карар нигезендә ачык сервитут йогынтысы өлкәсе турында тиешле белешмәләр кертү өчен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен котрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**